# ТАТАР ҺӘМ БАШКОРТ ТЕЛЛӘРЕНДӘ
# ИЯРТҮЧЕ ТЕРКӘГЕЧЛӘР ҺӘМ ТЕРКӘГЕЧ СҮЗЛӘР

**З.Н.КИРИЛЛОВА**

(Казан (Идел буе) федераль ун-ты, Казан ш.)

**Резюме.** Статья посвящена исследованию подчинительных союзов и союзных слов в татарском и башкирском языках. В работе находят свое отражение разные классификации союзов и союзных слов в сравниваемых языках. Автор приходит к выводу, что различие во мнениях вызывает трудности как в конкретном разграничении подчинительных союзов и союзных слов, так и в преподавании татарского и башкирского языков в различных учебных заведениях.

**Ключевые слова**: подчинительный союз, союзное слово, татарский язык, башкирский язык, тюркские языки.

**Summary**. Article is devoted research of subordinating conjunctions and connective words in the Tatar and Bashkir languages. In work find the reflection different classifications of the unions and connective words in compared languages. The author comes to a conclusion that distinction in opinions causes difficulties as in concrete differentiation of subordinating conjunctions and connective words, and in teaching of the Tatar and Bashkir languages in various educational institutions.

**Keywords**: subordinating conjunction, a connective word, the Tatar language, the Bashkir language, Turkic languages.

Татар һәм башкорт телләре, күренекле тюрколог Н.А.Баскаков классификациясе буенча, төрки телләрнең кыпчак-болгар төркемчәсенә кертелә [Баскаков 1988: 120-121]. Әлеге ике тел үзара бик якын булса да, ияртүче теркәгеч һәм теркәгеч сүзләрне билгеләү мәсьәләсе аларда төрлечәрәк хәл ителә.

Башкорт тел белеменә караган хезмәтләрдә ияртүче теркәгечләрне төркемләүдә кайбер үзенчәлекле яклар күзәтелә. Мәсәлән, Н.К.Дмитриевның

“Грамматика башкирского языка” хезмәтендә ияртүче теркәгечләрнең 4 төркеме генә аерып чыгарыла: сәбәп (*сөнки*), нәтиҗә (*хатта, шулай ук, ахыры, бит, ки*), шарт (*әгәр, әгәр зә*[1]), кире шарт (*гәрсә, хатая*) [Дмитриев 1948: 129]; Р.Н.Терегулова һәм К.З.Әхмәров авторлыгында язылган рус һәм башкорт телләренең чагыштырма грамматикасында төркемчәләр саны 6: сәбәп (*сөнки*), нәтиҗә (*шуга күрә, шул тиклем*), ачыклаучы (*гүйә*), аныклаучы (*йәгни*), шарт (*әгәр, әгәр зә*), кире шарт (*гәрсә, исмаһам*) [Терегулова 1953: 167-168]; “Грамматика современного башкирского литературного языка” хезмәтендә исә теркәгечләр төркемчәләп тикшерелми, һәр теркәгечкә аерым-аерым характеристика бирелә, шулай да әлеге тикшеренүдә түбәндәге төркемчәләр хакында нәтиҗә чыгарырга мөмкин: шарт теркәгечләре (*әгәр, әгәр зә, әгәр зә мәгәр, гәрсә*), сәбәп (*сөнки*), чагыштыру (*гүйә, гүйәки*), нәтиҗә (*шуга, шуга күрә, шуга ла, тимәк, шуның өсөн, шунлыктан, шуның һөзөмтәһендә, шул аркала, шулай булгас*), *тип* сүзе теркәгеч функциясендә кулланыла дип аерып күрсәтелә [Грамматика 1981: 357-358].

Башкорт теле морфологиясе буенча иң соңгы хезмәтләрдән саналган “Хәзерге башкорт әзәби теле”ндә бары 4 төркемчә тәкъдим ителә: шарт (*әгәр, әгәр зә, әгәр зә мәгәр*), сәбәп (*сөнки*), чагыштыру (окшатыу) (*гүйә, гүйәки*), нәтиҗә (һөзөмтә) (*хатта, шуга, шуга ла, шуга күрә, шуның өсөн, шунлыктан, шуның һөзөмтәһендә, шул аркала, шулай булгас*). Хезмәттә шулай ук һәр теркәгечкә аңлатма да бирелә. Мәсәлән: “*гүйә, гүйәки* – был теркәүестәр бер нәмәне йәки эш-хәлде икенсеһенә сагыштырганда, окшатканда кулланылып, *кеүек, шикелле, әйтерһең дә* тигән мәгәнә бирә”. Бары шушы хезмәттә генә *ки* теркәгеченең искергән сүзләр рәтенә керүе, хәзерге башкорт әдәби телендә сирәк кулланылуы билгеләнә, мисал итеп 1929 елгы җөмлә китерелә [Зәйнуллин 2002: 346-348].

Күренгәнчә, башкорт тел гыйлемендә ияртүче теркәгечләрне төркемләү төрлечә хәл ителә, ләкин күзәтү ясалган хезмәтләрнең барысында да шарт, сәбәп һәм нәтиҗә теркәгечләре аерып чыгарылган, кире шарт төркемчәсе

---

[1] Башкорт теле шрифты булмау сәбәпле, үзенчәлекле хәрефләр татар теленә яраклаштырып бирелде.

беренче ике хезмәткә генә, ә чагыштыру теркәгечләре соңгы ике хезмәткә хас. Ачыклаучы теркәгечләрне билгеләү, безнеңчә, рус теле тәэсирендә булырга тиеш. Тагын шунысы игътибарны җәлеп итә: башкорт телендә шарт, кире шарт яки чагыштыру теркәгечләре дип билгеләнгән бәйләүче чаралар нигездә татар телендәге теркәгечләр белән тәңгәл килә, ә нәтиҗә теркәгечләре дип аерып чыгарылганнарының зур күпчелеге исә татар тел белемендә мөнәсәбәтле сүзгә кертеп тикшерелә.

Татар телендә ияртүче теркәгечләр синтаксик функцияләре буенча ике төркемгә туплап бирелә: 1) билгеле бер мәгънә мөнәсәбәтен белдерә торган теркәгечләр (сәбәп-нәтиҗә: *чөнки, ник дисәң*; шарт: *әгәр, әгәренки*; кире шарт: *гәрчә*; аныклаучы: *ягъни, аеруча, бигрәк тә, башлыча, хәтта* һ.б.) һәм 2) берничә мәгънә мөнәсәбәтен бирүдә, ягъни төрле иярчен җөмләләрне төзүдә катнаша торган теркәгечләр (*гүя, гүяки, әйтерсең, диярсең, ки*) [Татарская 1993: 335].

Башкорт теле буенча тикшерелгән хезмәтләрнең берсендә дә ияртүче теркәгеч сүзләр аерып чыгарылмый. Татар теле грамматикаларында исә төп каршылык беренче чиратта шул мәсьәлә нигезендә барлыкка килә. Мәсәлән, “Татар грамматикасы”ның III томында һәм М.З.Зәкиев хезмәтләрендә ияртүче теркәгечләргә чөнки, гүя, ки, ягъни; ә ияртүче теркәгеч сүзләргә хәтта, хәер, юкса, бигрәк тә, аннан да бигрәк, әйтерсең, башкача, башкача әйткәндә, ул да түгел, җитмәсә, әйтәм (лә), аеруча, һәрхәлдә, димәк бәйләүче чаралары кертелә [Татар 1999: 359-363; Зәкиев 2005: 257-259]. “Татар грамматикасы”ның II томында С.М.Ибраһимов тарафыннан ияртүче теркәгечләргә чөнки, гүя, әгәр, әгәренки, гәрчә, ки, әйтерсең, диярсең, күрәсең, ул да түгел сүзләре кертелә, ә ягъни, мәсәлән, димәк, аеруча, башкача әйткәндә һ.б. аныклаучы теркәгечләр дип санала; сорау алмашлыклары белән бирелгәннәре исә теркәгеч сүз дигән атама ала [Татар 2002: 335-341]. Безнең фикеребезчә, С.М.Ибраһимов классификациясендә ияртүче теркәгеч һәм теркәгеч сүзләрне аеруның төп билгеләре рус тел белеме белән нигездә уртак булса да [Современный 2002: 198-199], әлеге

төркемләү беренчесенә караганда төгәлрәк һәм дәлиллерәк. М.З.Зәкиев классификациясендә тәкъдим ителгән теркәгеч сүзләрнең күбесе әлеге бәйләүче чара таләпләренә җавап бирми. Мәсәлән, *юкса, югыйсә, ул да түгел* сүзләре баш җөмлә составында урнаша, мәгънәдәш мөнәсәбәтле сүзләр белән алыштырыла ала, синтетик җөмләгә үзгәрткәндә дә, аларга мөнәсәбәтле сүз сыйфатлары хас икәнлеге күренә. *Әйтерсең* бәйләүче чарасы *гүя* иярүче теркәгече белән алыштырыла ала, димәк, аны шул төркемгә кертеп билгеләү дөресрәк булыр иде. *Хәер, һәрхәлдә, димәк, җитмәсә, әйтәм (лә)* кебек сүзләр күпчелек очракта кереш сүз функциясен генә үтиләр, моннан тыш, алар баш җөмлә составында киләләр, бу исә, *ки* теркәгеченнән тыш, барлык иярүче теркәгечләрнең иярчен җөмләдә урын алу тәртибенә каршы килә һ.б.

Кыпчак-болгар төркемчәсенә кергән ике кардәш телдә иярүле мөнәсәбәтне белдерә торган теркәгеч һәм теркәгеч сүзләрне билгеләү үзенчәлекләрен ачыклаганнан соң, түбәндәге нәтиҗәгә килергә мөмкин: башкорт грамматикаларында нәтиҗә теркәгечләре дип күрсәтелгән бәйләүче чараларның барысы да диярлек татар телендә мөнәсәбәтле сүз буларак тикшерелә, күзәтү ясалган башкорт хезмәтләрендә иярүче теркәгечләрнең мәгънә ягыннан төркемчәләрен билгеләүдә генә аерымлыклар урын ала, татар тел белемендә исә төп авырлык иярүче теркәгечләрне һәм теркәгеч сүзләрне аеру мәсьәләсендә барлыкка килә. Татар грамматикасының ике томы арасында кискен каршылык булу уку һәм укыту процессында зур авырлыклар тудыра, татар тел белемендә иярүче теркәгеч һәм теркәгеч сүзләрне төгәл билгеләргә мөмкинлек калдырмый һәм бу мәсьәләдә уртак фикергә килүне таләп итә.

## ИСКӘРМӘЛӘР

*Баскаков Н.А.* Очерки истории функционального развития тюркских языков и их классификация. – Ашхабад: Ылым, 1988. – 140 с.

*Грамматика* современного башкирского литературного языка. – М.: Наука, 1981. – 495 с.

*Дмитриев Н.К.* Грамматика башкирского языка. – М.-Л.: Наука, 1948. – 276 с.

*Зәйнуллин М.В.* Хәзерге башкорт әзәби теле: Морфология /Югары укыу йорттарының филология факультеты студенттары өсөн дәреслек/. – Өфө: БДУ, 2002. – 388 б.

*Зәкиев М.З.* Татар синтаксисы: Югары уку йортлары өчен д-лек. – Казан: Мәгариф, 2005. – 399 б.

*Современный* русский язык: Теория. Анализ языковых единиц: Учеб. для высш. учеб. заведений: В 2 ч. – Ч. 2: Морфология. Синтаксис / В.В.Бабайцева, Н.А.Николина, Л.Д.Чеснокова и др.; Под ред. Е.И.Дибровой. – М.: Академия, 2002. – 704 с.

*Татар* грамматикасы. Т. II. – М.: Инсан, Казан: Фикер, 2002. – 448 б.

*Татар* грамматикасы. Т. III. – М.: Инсан, Казан: Фикер, 1999. – 512 б.

*Татарская* грамматика. Т. II. Морфология. – Казань: Тат. кн. изд-во, 1993. – 397 с.

*Терегулова Р.Н., Ахмеров К.З.* Сравнительная грамматика русского и башкирского языков. Под ред. Н.К.Дмитриева. – Уфа: Башкир. кн. изд-во, 1953. – 208 с.